**ГЛАВА БОЛЬШЕПОДБЕРЕЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ПОДБЕРЕЗЬЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«05» ноябрь, 2020 ел Олы Подберезье ав. № 6

Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье Башкарма комитетының «Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Олы Подберезье торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җыенын билгеләү турында» 2020 елның 20 октябрендәге 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье Башкарма комитетының «Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Олы Подберезье торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җыенын билгеләү турында» 2020 елның 20 октябрендәге 5 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 3.1. п. өстәргә. 2020 елның 12 ноябрендә 11 сәг 00 минутка, 16 сәг 30 минутка ТР, Кайбыч районы, Олы Подберезье ав., Ирек мәйданы ур., 31нче йорт адресы буенча урнашкан Олы Подберезье мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең Олы Подберезье торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча ике гражданнар җыенының ***дүртенче этабын*** билгеләргә.
2. 3.2. п. өстәргә. 2020 елның 12 ноябрендә 11 сәг 00 минутка ТР, Кайбыч районы, Олы Подберезье ав., Ирек мәйданы ур., 31нче йорт адресы буенча урнашкан Олы Подберезье мәдәният йорты бинасында Татарстан

Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең Олы Подберезье торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының ***бишенче этабын*** билгеләргә.

3. 4 пунктка «Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру» г» пунктчасын өстәргә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- суэтем башнясын лицензияләү өчен (су белән тәэмин итү чыганагы артскважинасын куллануга, суны һәм башка документларны анализлауга санитар-эпидемиологик бәяләмәне документаль рәсмиләштерүгә) түләү.

4. Әлеге карарны Олы Подберезье авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар бастырып чыгарылган көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының
Олы Подберезье авыл җирлеге Башлыгы О.М. Емельянова